Татарстан Республикасы Милли архивы фондында мөселман метрика язмалары



Татар тарихи чыганакларының бер өлеше шактый тәфсилле итеп тикшерелсә дә, әле һаман да кул житмәгәннәре бар. Яисә кайберләре еш кулланылып та, махсус тикшерү объекты булмаганнар. Шундыйлардан, метрика язмалары бик мөһим һәм махсус өйрәнүгә күптән лаеклы чыганаклардан берсе.

Метрика язмалары (бу очракта мөселман метрика язмалары турында гына сүз алып барыла) — мәчеттә мулла тарафыннан аерым бер мәхәлләдә туган, үлгән кешеләрне, укылган никахларны, талакларны теркәгән документ. Хәзерге вакытта бу вазифаларны ЗАГСлар башкара.

Мондый документлар Татарстан республикасы Милли архивының аерым фондын (4 ф. Казанская духовная консистория) алып тора. Бу фондтагы мөселман метрикаларының саны 2 000 нән артык. Милли архивта Россиядәге татар халкы яшәгән күп кенә авылларның шундый язмалары саклана. Әлбәттә, сан ягыннан иң күбе, тулылыгы белән дә беренче урында торучысы — Казан губернасы авылларының метрика язмалары. Аерым алганда, Казан шәһәре, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш, Чистай өязләре язмалары әйбәт сакланган. Чар (Царевококшайск), Чуел (Цивильск) өязләренеке бераз азрак һәм иң азы — Чабаксар өязенеке, бу төбәк буенча безнең көннәргә бары тик 1881 һәм 1915 елгы язмалар гына килеп житкән. Казан губернасыннан кала, иң әйбәт һәм чагыштырмача тулы сакланган-

нардан — Уфа губернасының Минзәлә, Самара губернасының Бөгелмә өязе документлары. Шулай ук Сембер губернасының Буа, Карсун, Курмыш, Сембер, Вятка губернасының Алабуга, Сарапул өязләре буенча да язмалар Милли архивта урын алганнар. Вакыт ягыннан караганда, Татарстан республикасы Милли архивында метрика язмалары 1865 елдан башлап кына сакланган, ләкин шулай да 4 нче фондның 6, 7, 8, 9, 10, 15 нче өстәмә тасвирламаларыннан күренгәнчә, аерым авыллар буенча иң борынгысы дип 1829 елны атый алабыз. Саклану дәрәҗәсенә килгәндә, 1916-1917 елларга кадәрге документлар тулы, пөхтә итеп эшләнгән. Россиядә 1917 ел үзгәрешләре метрикаларның кыяфәтендә дә чагыла: бу чордан соңгы документларда аларга куелган таләпләр тиешле дәрәҗәдә үтәлмәве күзгә чалына, хәтта почеркларның ямьсезләнүе күренә. 1917 елдан соңгы документлар тулы сакланмаганнар, кайбер авыллар буенча документлар бөтенләй юк, сакланганнарының да физик халәтләре мактанырлык түгел. Татарстан республикасы Милли архивында тулы булмаган рәвештә генә булса да, 1922 елга кадәрге документлар бар, ләкин бик күп авылларның метрика язмалары 1920 ел белән төгәлләнәсә дә, бик сирәк очракта гына 1924 елга кадәрге язмалар очрый.

Югарыда әйтелгәнчә, метрика ул — документ, шулай булгач, аның үзенең язылу тәртибе һәм кагыйдәләре булган. 1916 елдан башлап, Диния нәзарәте тарафыннан метриканы саклау, язу һәм язганда игътибар ителергә тиешле нәрсәләрне белү имамлыкның имтихан программасына кертелә. Бу таләпләр куелганнан соң, метрика язмалары махсус тикшерелгән һәм бу оешма нәшер иткән журнал битләреннән күренгәнчә, әгәр дә хата җибәрелә икән, теркәүче җавапка тартылырга тиеш булган[1].

Метриканың структурасына килгәндә, иң беренче мәгълүмат булып, туучылар теркәлгән. Моның шулай ук үз тәртипләре булган. Ир һәм кыз балаларның исемнәре аерым номер белән теркәлгән, ягъни баланың кайсы җенестән икәнен номерлар буенча да белергә мөмкин. Ләкин моннан тыш, кайбер очракта һәр исемнең астына кыз бала яисә ир бала дип тә язып куелган. Бу исә, мәҗбүри түгел, әгәр дә бертөрле исем ир балаларга да, кыз балаларга да кушылу ихтималы булган очракта, буталмас өчен кирәк. Мондый исемнәр татарларда, еш булмаса да, очраштыргалый. Мәсәлән, Миңлесафа, Гайнекамал һ. б. Туган баланың әтисе, әнисе һәм бабаларының исемнәре язылган. Борынгырак документларда, бабаларының исемнәре күрсәтелмәгән. Соңрак, ягъни 1917 елдан соңгы документларда, фамилия дә языла башлый, ләкин бу һәр вакытта да эшләнмәгән. 1916 елгы «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя» журналы язуынча, «әлегә кадәр татар халкында фамилия йөртү мәҗбүри түгел иде, ләкин хәзерге вакытта, рәсми эшләрдә, бигрәк тә гаскәргә алынган вакытта, фамилия кирәк була. Әгәр дә атасының әүвәлдән килгән фамилиясе булса, аңа шул фамилия бирелә яки бабасының исеме фамилия итеп алына». Бала метрика саклана торган мәхәлләдә туса, аның адресын тәфсилләп язу мәҗбүри түгел. Әгәр ул читтән килгән икән, бигрәк тә Казан шәһәре метрикаларында, әтиләре кайсы төбәктән килгәне күрсәтелә.

Диния нәзарәте, баланың исеме янында аның әтисенең социаль катлавын мещан, дворян, почетлы гражданин булган очракларда гына күрсәтүне, таләп иткән[2]. Ләкин метрика язмаларыннан күренгәнчә, муллалар башка катлауларны да теркәп барганнар. Мәсәлән, крестьян яисә зирагатьче, имам, старшина, мәзин, башкорт, типтәр һ. б.

Балага исем кушу мәсьәләсе дә аерым каралган. Беренчедән, мөселманча күркәм исемнәр кую таләп ителсә, икенчедән, ул исемне дөрес кулланып, төгәл язу шарт итеп куелган[3]. Балага исем куштыру артыннан йөргән кеше (әтисе яки бабасы) мулла кушкан һәм теркәгән исемне укып, дөреслегенә инанып кул куярга тиеш булган[4].

Татар халкында «бәби ашы» (яисә «бәби чәе») уздыру гадәте бар. Шул ук «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя» журналы язуынча, бу эш шәригатькә каршы килми, ләкин болай эшләүнең тискәре ягы да барлыгын искәртә. Балага азан әйтеп исем кушуны, кунак җыю белән туры китерергә

тырышып, балага исем кушу һәм аны теркәү кичектерелеп торырга мөмкин, ягъни бала хәтта үзе туган елны теркәлми дә кала, әгәр бала туган елында метрикага теркәлми икән, аны киләсе елгы метрикага кертә алмыйлар. «Мәгълүмәте мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя» бу хакта «бу хосуста бик зур эшләр йөртелгәне бар, бик зур дәрәҗәле кешеләр, үз вакытында метрикага язылмый калган балаларын, соңыннан метрикага кертергә теләп эш йөрткәннәре бар, ләкин нәтиҗә чыкмады»[5], дип яза.

Егетләргә никах 18 яшьтән укылган, 80 яшьтән узганнарга бу гамәл рөхсәт ителмәгән. Никахны теркәү өчен яшь хакында белешмә таләп ителә[6] — бу беренчедән, ә икенчедән, икесенең дә мөселман булуы, һәм аларның шаһитлары булу шарт[7]. Беренче графага никах укылу датасы, егет һәм кызның яшьләре языла. Икенче графага никахлашучыларның адреслары һәм исемнәре теркәлә. Никахланышучылар, метрика саклана торган мәхәллә кешеләре булсалар, аларның тәфсилле адреслары таләп ителмәгән. Әгәр дә алай түгел икән, адрес төгәл күрсәтелергә тиеш (губерна, өяз, волость, авыл исемен күрсәтү мәҗбүри), хәтта авылның рәсми исеменнән тыш, халык арасындагы исемен дә күрсәтү кирәк була. Никах, нигездә кыз ягында рәсмиләштерелгән, ләкин егет ягында теркәлгән очраклар да булган. Никахлашучыларның ничәнче никахы икәнлеге дә күрсәтелә. Никахның шаһитлары билгеләнә, алар ике төрле: бер төре вәли вәкил дип атала, нигездә, мондый шаһитлар егет һәм кызның әтиләре була. Кайбер очракта мондый вазифаны бертуганнары да үти алган. Вәли вәкил буларак егет үзе дә чыгыш ясый алган, ләкин кызның үзенә-үзе вәли вәкил булуы чиктән тыш сирәк хәл, бу бары тик 1917 елдан соң гына аз-маз күренгәли башлый. Икенче төр шаһитлар — ризалык шаһитлары, һәр ике яктан да икешәр, ә кайбер очракта дүртәр шаһит билгеләнгән — болар туганнар, күршеләр яисә мәҗлестә катнашкан таныш-белешләр. Бу шаһитлар никахка хәер-фатиха бирәп, үз имзаларын яисә тамгаларын куялар, әгәр дә алар чит мәхәллә кешеләре булса, төгәл адреслары языла. Аерым графада мәһәрнең күләме күрсәтелә. Гадәттә, мәһәр малы ике өлештән торган: бер өлеше никах укыган вакытта бирелгән, ә икенче өлеше көтәчәк мал дип аталган. Мәһәрне алучы «...кадәр мәһәрне хәзер алдым», — дип, ә бирүче «...кадәр мәһәр бирәсе калды», — дип имзасын куйган. «Көтәчәк мәһәр хатынның ир өстендәге бурычы булып, бер тараф үлгәндә, яхуд аерылышканда ул мәһәр хатын файдасына буладыр. Авылларда мәһәр итеп ат, сыер, түшәк, ястык һ. б. шундый нәрсәләр язылса, аның кыйммәте язылып бәян ителергә тиеш. Ат, сыер төсе белән язылса яхшы булыр»[8] диелә Диния нәзарәте таләбендә. Соңгы графада никах хөтбәсен укыган имамның имзасы куела. Никахны теркәү өчен 25 тиен пошлина алынган[9].

Метрикада талак өчен махсус бүлек бар. Монда аерылышу датасы төгәл күрсәтелергә тиешле, ул дөрес күрсәтелмәгәндә, көтелмәгән хәлләргә сәбәп булуы да ихтимал. Аерылу эшләре ир кеше һәм хатынның атасы арасында алып барыла, ә хатын исә бу хәлләргә турыдантуры катнашмый. Ләкин бу һич кенә дә аның әлеге эшләрдә хокуксыз булуын аңлатмый. Бары тик ислам тәртипләре буенча ана булган яисә киләчәктә ана буласы хатын-кызлар һәртөрле күңелсез хәлләрдән, стресслардан мөмкин кадәр сакланган, шуңа да аерылышу хәлләрендә хатын-кызның барлык таләпләре әтисе аша җиткерелгән, һәм ул һәрвакыт үзенә тиешлесен ала алган. Талакка да никахтагы кебек шаһитлар кирәк һәм аларның халык тарафыннан хөрмәткә лаеклы кешеләр булуы шарт. Алар үзләренең шаһитлыгын раслап имза яки тамга куялар. Шаһитлар нигездә ике кеше була. Аерым графа итеп аерылышуның сәбәбе күрсәтелә. Күп очракта «арада мәхәббәт юклык сәбәпле» дип языла, ләкин Диния нәзарәте фикеренчә, нәкъ менә шушы сүзләр астында мөһим сүзләрне яшереп калдыралар, аерылышуга китергән сәбәпләрне төгәл ачыкларга тырышу кирәк диелә[10]. Талакны рәсмиләштергән имамның да имзасы куела. Шуны да әйтергә кирәк, 1917 елга кадәр талакларның саны чагыштырмача аз, аннан элеккерәк чорда бөтенләй юк диярлек, күп дигәндә бер мәхәлләдә елына 1-2 талак булырга мөмкин, ә 1917 елдан соң аларның саны бермә-бер арта.

Иң соңгы бүлектә вафат булучыларның исеме теркәлгән. Кеше дөньядан китсә дә, аның үзеннән соң балалары, малы кала. Менә шушы мәсьәләдә аңлашылмаучанлык килеп чыкмасын өчен, кешенең үлү көне, исеме, әтисенең исеме төгәл язылырга тиеш. Хатын-кыз кияүгә чыгу белән ире фамилиясенә күчсә дә, аның үз ата-анасы белән мөнәсәбәте элеккечә кала, Диния нәзарәте таләбе буенча, хатын-кыз ике фамилия белән язылырга тиеш[11]. Метрикада фәлән кешенең хатыны һәм фәлән кешенең кызы дип бирелә. Шулай ук мал бүлгәндә, аңлашылмаучанлык килеп чыкмасын өчен, бу кешенең төгәл яшен һәм кайда җирләнүен дөрес күрсәтү таләп ителгән. Авылда охшаш исем-фамилияле кешеләр дә булгалый, моннан тыш үлгән беренче баланың исемен аннан соң туган башка балага кушу очраклары татарда шактый еш очрый, шуңа да буталу килеп чыгу мөмкин. Вафатлар бүлегенең бишенче графасында кешенең нинди авырудан вафат булуы язылган. Борынгырак чорда халык профессиональ табибларга мөрәҗәгать итмәгәндә үлемгә китергән сәбәпне төгәл ачыклап булмаган, ләкин соңгырак чорда вафатның сәбәпләре төгәлрәк күрсәтелә башлый. Шулай да авыру ачыкланмаса, ул графаны буш калдыру мөмкинлеген Диния нәзарәте рөхсәт итә[12]. Иң еш очраган авырулар кызамык, чәчәк, ютәл, зыяндаш, салкын тию һ. б. 1920-1921 еллардагы метрикаларга күз салганда, үлү сәбәбе графасына тоташ «ачлыктан» дигән сүз язылган. Бер көн эчендә генә дә бер гаиләдән дүрт кешегә кадәр вафат булу очраклары күренде.

Метрикаларның чыганак буларак әһәмиятләре, һичшиксез, югары. Бу документлар статистик мәгълүмат кына биреп калмый, татар җәмгыятенең яшәү рәвешен, гомумән, тарихын тәфсилләп өйрәнергә мөмкинлекләр ача. Шулай да аларның иң кызыклыларына гына тукталып китәбез. Беренчедән, социаль катлаулар мәсьәләсе, бигрәк тә «башкорт» катлавы. Бу сүзнең эчтәлеге хәзергә кадәр гади халык һәм хәтта төбәкне өйрәнүчеләр тарафыннан да аңланмый, хәзерге башкорт халкы белән тәңгәлләштерелеп, тарихи ялгышларга китерә. Сембер губернасының кайбер авыл (мәсәлән, Кече Тархан авылы) метрика язмаларында кеше исемнәре янына аларның кушаматларының да язылуы — аеруча кызыклы күренеш.

Метрика кенәгәләрендә вафат булучыларның яшенә игътибар итсәк, бу язмалар буенча шул чорның гомер озынлыгын да ачыкларга мөмкинлек туа. Метрика язмаларында илле биш, алтмыш яшьлекләрнең вафат булу сәбәбен күрсәткәндә, «картлыктан» дип язу үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Туксанга җитеп вафат булучылар да очрый, ләкин андыйларның саны күп түгел. Балаларның кече яшьтә авырып вафат булу очраклары еш күзәтелә.

Никахлашуларга килгәндә, беренчедән, яшь мәсьәләсе игътибарны җәлеп итә, икенчедән, никахлашу географиясе кызыклы. Кызларга 16 яшьтән никахка керергә рөхсәт ителгән, әмма әлегә кадәр метрика язмаларында кызларның 18 яшьтән дә иртәрәк кияүгә чыгулары очрамады. Тагын кызыклы гына бер факт: халык арасында егет кыздан олы булырга тиеш дип кабул ителгән, ләкин шул ук метрика язмаларында бу хәлнең еш кына киресе күзәтелә. Никахлар, нигездә, күрше-тирә авыллар белән барган, ләкин кайчакта бик ерак төбәктән булганнар белән дә кавышулар очрый.

Имза урынына куелган тамга — үзе үк тирәнтен фәнни өйрәнүне таләп итә, чөнки аларның төрләре, үзгәрешләре бик кызыклы. Бары тик тамгага гына карап та, бер үк нәсел кешеләрен ачыклап була, хатын-кызлар куя торган тамгага аерым игътибар итү кирәк, чөнки теләсә нинди губернаның теләсә нинди авылында яшәүче хатын-кызның тамгасы бер үк. Димәк, бу тамганың кызыклы, тирән, борынгы тарихы барлыгы шөбһәсез.

Метрика язмаларында татар халкы тарихындагы фаҗигале вакыйгалар да чагыла. Мәсәлән, Әлки авылының Яңа Әнҗерә авылының 1906 елгы метрикасына соңга калып булса да, XIX йөздә туган мәкрүһләр (ислам диненә кайтучылар) теркәлә һәм шул ел метрикасында аларның төгәл туу еллары күрсәтелә.

Хәзерге Алексеевский районы Шама авылының 1882 елгы метрикасында (гомумән, бу авылның мөселман метрика язмасы булу үзе үк кызыклы, чөнки белешмәлекләргә күз салсак, бу авылда

руслар һәм чуашлар яши) гарәп язуы белән христиан исемле кешеләр язылган. Мәсәлән, Шама авылының мөселман метрикасында Герасимның яше 47 дип куелган, ягъни ул мөселманлыкка чыккан христиан булган булырга тиеш.

Метрика кенәгәләре авылның нигезләнү датасын күрсәткән белешмәләкләр төзегәндә дә файдаланылса, отышлы булыр иде. Кайбер очракта белешмә хезмәтләрдә күрсәтелгән авылның нигезләнү датасы аның архивта сакланган иң борынгы метрика кенәгәсеннән соңрак ел булып чыга.

Соңгы елларда татар тарихындагы күренекле шәхесләрнең тормыш юлын өйрәнеп нәшер ителгән басмалар еш күренә, бу очракта да метрика язмалары бик күп фактларны төгәл ачыкларга мөмкинлек бирә.

Иң мөһиме: хәзерге вакытта бигрәк тә популярлашып киткән нәсел шәҗәрәләрен эшләгәндә — бу язмалар кыйммәтле тарихи чыганаклар булып торалар.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Метрика дәфтәренә язу хакында Мәхкәмәи шәргыя тарафыннан тәнбиһ // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 2. – Б. 4-5.
2. Имамлык вә метрика язу эше // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 11. – Б. 16-21.
3. Метрика дәфтәренә язганда ригая кылынырга тиеш низамнар // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 4-5. – Б. 4-5.
4. Имамлык вә метрика...
5. Шунда ук.
6. Метрика язу ысулы // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 12-13. – Б. 22-27.
7. Метрика язу вә рәсми кәгазьләр йөртү хакында // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 20. – Б. 13-14.
8. Метрика язу ысулы... – Б. 22-27.
9. Никах акчалары хакында // Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя. – 1916. – № 23-24. – Б. 20-21.
10. Метрика язу ысулы...
11. Шунда ук. – № 16-17. – Б. 4-5.
12. Шунда ук.

Рәсем 34 б.: Мөселман метрика язмасының 1910 елгы үрнәге. ТМА, 4 ф., 180 тасв., 19 сакл., 208-209 кгз.

Эльмира Сәлахова,
тарих фәннәре кандидаты

РЕЗЮМЕ

В статье кандидата исторических наук Эльмиры Салаховой приводится анализ магометанских метрических книг, хранящихся в фондах Национального архива Республики Татарстан. Это метрические записи с 1829 по 1930 г. деревень и сел Казанской, Уфимской, Симбирской, Вятской губерний, количество которых составляет более 2 000 единиц. В статье автор делает акцент на особенностях магометанских метрических книг и правилах их составления.